| СОВЕТ<br>НИЖНЕВЯЗОВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КАРАМАЛЫ ТАУ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ**
**04.09.2023**

Карамалы Тау штп

**КАРАР**
**№ 168**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 22.06.2023 №157 «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 22.06.2023 №157 «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә тапшыру турында «карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге

автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга:

- чокыр ремонтлау;
- Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында тротуар төзелеше;
- Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы 3 км тимер юл кичүе янында юл билгеләре урнаштыру;
- ясалма тигезсезлекләр урнаштыру, тиешле юл билгеләре урнаштыру һәм Свердлов урамы буенча Түбән Карамалы Тау бистәсендә юл билгеләре салу.».

2. Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында өстәмә килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ административ бинасында мәгълүмат стенды, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

Җирлек башлыгы,
Совет Рәисе А.М. Гыйниятов